КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 ноябрь г.Казань № 1070

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күчемсез мөлкәтнең сәүдә объектларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору мөмкинлеген биргән салым түләүчеләр исемлеген формалаштыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләү шартларына һәм аны кичектереп тору вакытларына карата таләпләр билгеләү турында» 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы карары белән расланган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләү шартларына һәм аны кичектереп тору вакытларына карата таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күчемсез мөлкәтнең сәүдә объектларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору мөмкинлеген биргән салым түләүчеләр исемлеген (алга таба – исемлек) формалаштыру тәртибен (карарга теркәлә) расларга

2. Исемлекне формалаштыру буенча вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин